СИШӘМБЕ
30 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 24 (5824)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

СОЦИАЛИСТИК ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ЭШЕНӘ БОЛЬШЕВИСТИК ҖИТӘКЧЕЛЕК

Партиянең тарихи XVIII нче съезды социалистик авыл хуҗалыгы алдына политик әһәмияте гаять зур булган бурычны: СССР да терлекчелек проблемасын өченче бишьеллыкта тулысынча хәл итү бурычын куйды.

Сталинчыл өченче бишьеллыкның ахрына терлекчелек өлкәсендә безнең илебез түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә тиеш: атлар саны 35, мөгезле эре терлекләр саны 40, дуңгызлар саны 100, сарык һәм кәҗәләр саны 110 процент үсәргә тиеш. Терлекләрнең санын арттыру белән берлектә, аларның нәселлелеге һәм продуктлылыгы өлкәсендә дә эш тамрыннан яхшыртылырга тиеш. Мондый зур күтәрелешне, үсешне билгеләгән Сталинчыл бу бөек планны үтәү һәм арттырып үтәү өчен безнең илебездә шул исәптән безнең республикабызда да, бөтен шартлар һәм мөмкинлекләр бар.

Сталинчыл бишьеллыклар чорында колхоз авылында, совхоз, колхоз фермаларында социалистик терлекчелекне үстерүдә, аңардан югары доход алуда, терлекнең сыйфатын яхшыртуда, продуктлылыгын күтәрүдә сокланырлык эш үрнәкләре биргән кадрлар: сыер сауучылар, ат караучылар, дуңгыз тәрбияләүчеләр, чабаннар, ферма мөдирләре, бригадирлар үсеп чыктылар һәм аларның иң яхшылары илебезнең иң югары бүләге белән—Советлар Союзы орденнары белән бүләкләнделәр. Арча районының Тельман исемендәге колхозның куян фермасында элек мөдир булып эшләгән Баян Нуриҗанованы, Калинин районы „Татарстан" колхозы ферма мөдире Бибикованы, Чистай районы, „Урожай" колхозының сарык фермасы мөдире Никитинны, „Татарстан" совхозы сыер сауучысы Сабитованы, Баулы районы, Буденный исемендәге колхозның ат караучысы Малаховны республикабызның барлык хезмәт ияләре яхшы беләләр. 1939 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә Татарстан АССР колхозларыннан 119 терлекчелек фермалары һәм аларның алдынгыларыннан йөзләрчә работниклар катнашып, үзләренең үрнәкле эш тәҗрибәләрен, бөек казанышларын бөтен илебез алдында күрсәттеләр. Күргәзмә авыл хуҗалыгы өлкәсендә яңа кадрларның үсеп чыгуына ярдәм итте. Мисальгә Әтнә районының Ленин исемендәге колхозының сөтчелек фермасын, Чапаев исемендәге колхозның сарык асраучылык фермасын, Чаллы районының „Ташкичү" колхозының сөтчелек фермасын алырга мөмкин. Бу фермалар күргәзмәдә алган тәҗрибәләрен үзләренә күчерү, эшне дөрес оештыру, социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә, 1939 нчы елда дәүләт планын 121—130 процент итеп үтәүгә ирештеләр.

Теләче районы „Марс № 2" колхозы чабаны иптәш Якупов соңгы ике ел эчендә һәрбер 100 сарыктан 134 баш бәрән, Яңа Писмән районы, „Уныш" колхозы чабаны иптәш Әюпов һәр 100 сарыктан уртача 160 баш бәрән, һәрбер сарыктан 3,38 килограмм йон, Чистай районы, „Урожай" колхозы сарык асраучылык фермасы мөдире орденлы иптәш Никитин һәр 100 сарыктан 171 баш бәрән үстерүне тәэмин иттеләр. Кайбыч районы сыер сауучысы иптәш Гыймадова һәрбер сыердан елына уртача 2.556 литр, Минзәлә районы Ленин исемендәге колхоз фермасы мөдире һәрбер сыердан уртача 2.207 литр, Куйбышев районының „КИМ" совхозында терлекчелек бригадиры иптәш Медведева 100 сыерның һәрберсеннән уртача 3.689 литр сөт савып алуга иреште.

Мондый мисалләрне терлекчелекнең барлык төрләреннән дә китерергә мөмкин. Бу фактлар терлекчелекне тагын да көчле адымнар белән үстерү өчен бездә нинди зур мөмкинлекләр барлыгын бөтен ачыклыгы белән раслыйлар.

Партиябезнең, хөкүмәтебезнең көндәлек булышлыгы нәтиҗәсендә республикабызда социалистик терлекчелек эше бер туктаусыз алга бара, үсә һәм ныгый.

1940 нчы елның 1 нче гыйнварына Татарстан АССР да терлекләр санын алуның башлангыч йомгаклары колхозларның җәмагатьләштерелгән секторында терлекләрнең шактый үсүен күрсәтә. 1939 нчы елда атлар саны 17,2 процент, мөгезле эре терлекләр саны 16,7 процент, сарыклар—27,9 процент арткан. Терлекчелек өлкәсендә уңышлар зур. Ләкин бу, терлекчелек өлкәсендә кимчелекләр юк дигән сүз түгел. Терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планы 1939 нчы елны республикабызда үтәлеп җитмәде. Кайбер районнар бу хәлдән үзләренә карата тиешле нәтиҗә ясамадылар. Мәсәлән, Питрәч һәм Биләр районнарында товарлыклы-сөтчелек фермалары оештыру һәм аларда терлекләр санын үстерү планы 1939 нчы елда үтәлмәүгә дә карамастан, бу районнарның җитәкчеләре соңгы вакытларда да бу әһәмиятле эш белән канәгатьләнерлек шөгыльләнмиләр.

Терлекчелек өлкәсендә күренекле эш үрнәкләре биргән һәм 1940 нчы елда тагын да югарырак уңышларны яулап алу өчен большевистик көрәш җәелдергән колхозларның, совхозларның алдынгыларыннан йөзләрчә работниклар хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә катнашалар. Алар киңәшмәдә үзләренең эш тәҗрибәләре белән, социалистик терлекчелекне партиянең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган бурычлар югарылыгына күтәрү буенча җәелдерелгән көрәш методлары белән уртаклашалар.

Социалистик терлекчелекне 1940 нчы елда тагын да үстерү һәм ныгыту буенча республикабызның районнарында Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярыш җәелдерелде. Мәсәлән, Чистай районы, „Урожай" колхозының сарык асраучылык фермасында 1940 нчы елда һәрбер 100 сарыктан 180 баш бәрән алып үстерү, һәрбер сарыктан уртача 4,4 килограмм йон алу, дәүләт алдындагы йөкләмәләрне вактында һәм үрнәк рәвештә үтәү, фермада эшләүчеләрнең зоотехника белемнәрен күтәрү өчен ныклы көрәш бара. Фермадагы барлык работниклар да ярыш договоры белән чолгап алындылар.

Партия, совет оешмаларының бурычы: терлекчелек өлкәсендәге алдынгыларның бай тәҗрибәләрен киң күләмдә популярләштерүдән, аларны барлык фермаларда кулланыны оештырудан, социалистик ярышны, стахановчылык хәрәкәтен бөтен киңлеге белән җәелдерүдән гыйбарәт. „Терлекчелек эшен бөтен партия, безнең барлык работникларыбыз, партиялеләре дә һәм партиясезләре дә, үз кулларына алырга тиешләр..." (Сталин). Терлекчелек эшенә большевистик җитәкчелек тәэмин ителергә тиеш.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә. РӘСЕМДӘ: киңәшмә залының гомуми күренеше. М. Солтанов фотосы.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АЛДЫНГЫЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘГЕ КИҢӘШМӘСЕ

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенең кичә иртәнге утырышында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш Черзор председательлек итә. Киңәшмәдә беренче сүз иптәш Вәлиевкә бирелә. Ул 1939 нчы авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1940 нчы елгы бурычлар турында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеевның татарчага тәрҗемә ителгән докладын укыды.

Доклад буенча фикер алышулар башланды. Авыл хуҗалыгы алдынгылары үзләренең бай тәҗрибәләре турында, югары иген уңышы өчен, терлекчелектән бай доход алу өчен ничек көрәшүләре турында сөйлиләр. Алар үзләренең эшләреннән бик күп мисальләр һәм фактлар китерәләр. Алар агротехника чараларын бер-берсенә бәйләп кулланганда, безнең кырларыбыздан югары уңыш алырга мөмкин булуын үз тәҗрибәләрендә күрсәттеләр.

Әтнә районы Ленин исемендәге колхоз бригадиры иптәш Җәббаров югары уңыш өчен көрәштәге бай тәҗрибәләр турында сөйли. Ул үзенең речендә түбәндәгеләрне әйтә:

— ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты инициативасы буенча оештырылган безнең 8 кешелек бригада Белоглазов районы колхозларында ефремовчы звеноларның эш тәҗрибәсе белән танышу өчен Алтай краена барды. Без анда искиткеч яңалыклар күрдек. Ефремовчыларның югары уңыш алу өчен ничек көрәшүләре белән таныштык. Алар гектарыннан 70—80 центнер уңыш алганнар. Бу уңышка алар ничек ирешкәннәр соң? Агротехника чараларын төгәл тормышка үткәрү нәтиҗәсендә, бөтен эшне фән кушканча алып бару нәтиҗәсендә ирешкәннәр. Ефремовчыларның тәҗрибәсен без киң кулланырга, алар ирешкән уңышны яулап алырга тиешбез. Моңа бөтен мөмкинлекләр бар.

Буденный районы, „Гигант №2" совхозының агротехнигы иптәш Хафизов йөзпотчылар хәрәкәтенең киң җәелүе турында сөйли.

— Кырчылыктан күбрәк ашлык җинап алу безнең үз кулыбызда,—ди иптәш Хафизов,—моның шулай булуы турында мин „Гигант № 2" совхозыннан да бик күп мисальләр китерә алам. Барытик югары уңыш алу өчен большевистик тырышлык һәм энергия белән көрәшергә генә кирәк. Мин, агротехник буларак, шундый бер тәҗрибә ясап карадым: иген өлгереп җиткәч, урылмаган ашлыктан иң эре башакларны чүпләп алдым. Бу эре дип исәпләнгән башакларның эре бөртекләрен сайладым. Шушындый метод белән мин 15 кило орлык җинадым. Бу орлыкны без 0,33 гектар җиргә чәчтек. Шушы участкыдан 9 центнер 72 килограмм бодай уңышы җинап алдык. Бу факт үзе генә дә безнең басуларыбызда югары иген уңышы алуга чиксез мөмкинлекләр барлыгын бик ачык күрсәтә.

Чепья районы, „Крестьянская газета" колхозының яшелчәчелек бригадасы бригадиры иптәш Сафиуллин сүз ала. Ул яшелчәдән югары доход алу буенча бай тәҗрибәләре белән уртаклаша.

Минзәлә районының җир бүлеге агрономы иптәш Ерашов авыл хуҗалыгы белгечләре алдында торган гаять зур һәм мактаулы бурычларга тукталып үтә. Колхозларга белгечләр җибәрү буенча Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты җитәкчеләренең җитәрлек эшләмәүләрен тәнкыйтьли.

Чувашстан республикасы, Сталин исемендәге колхоз председателе иптәш Жарков киңәшмәдә зур речь белән чыкты. Бу колхоз гаять зур уңышларга ирешкән.

— Без соңгы ике ел эчендә һәрбер гектардан 20 центнер уңыш җинап алдык. Сталин исемендәге колхоз членнары 1940 нчы елда һәрбер гектардан 200 пот уңыш алу бурычын куйдылар. Без моңа тулысынча ирешербез. Авыл хуҗалыгы эшләрендә без фәннең соңгы казанышларыннан кыюлык белән файдаланабыз. Менә шуңа күрә дә без быел тагын да югары уңыш алуыбызга бик нык ышанабыз, ди иптәш Жарков.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсенең иртәнге утырышы шуның белән тәмам булды.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә сайлау кампаниясе

БРЕСТ. Шәһәрдә округ күләмендә 6 сайлау комиссиясе төзелде һәм расланды. Хезмәт ияләре сайлау комиссияләренә үзләренең вәкилләре итеп шәһәрнең иң яхшы кешеләрен җибәрделәр. Алар арасында Көнбатыш Белоруссия Халык Собраниесе депутатлары Савчук, Засимович, Рыбак һәм башка иптәшләр бар. Шәһәр Советы 35 сайлау участкысын төзүгә керешә.

Предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, җәмагат оешмаларында участкы сайлау комиссияләренең членлыгына кандидатлар күрсәтү башланды. Округ һәм участкы комиссияләрендә барлыгы 200 гә якын кеше эшләячәк.

ЛЬВОВ. Өлкәнең хезмәт ияләре округ күләмендәге сайлау комиссияләренең составына зур күтәренкелек белән үзләренең иң яхшы вәкилләрен билгеләделәр. 27 нче гыйнварда өлкә башкарма комитеты президиумы, ул комиссияләрнең составын раслады.

Шәһәрдә партиянең район җыелышлары булды. Бу җыелышларда коммунистлар сайлау кампаниясендә башлангыч партоешмаларның бурычларын тикшерделәр. 27 нче гыйнварда, шушы ук мәсьәләгә багышлап, бөтен шәһәр күләмендә партия көне үткәрелде. Хезмәт ияләренең политик активлыгы гаять дәрәҗәдә үсте. Халык сайлаулар турындагы положениене гаять зур кызыксыну белән өйрәнә. Фабрикаларда һәм заводларда Сталин Конституциясе турында беседалар үткәрелә. Һәр җирдә эшчеләрнең, эшче хатын-кызларның, интеллигенция вәкилләренең зур митинглары бара.

ПИНСКИЙ. СССР һәм БССР Верховный Советларына Белоруссиянең көнбатыш өлкәләреннән депутатлар сайлау буенча округ күләмендәге сайлау комиссияләре расланды. Комиссияләрнең составында „17 нче сентябрь" исемендәге шырпы фабрикасы эшчесе иптәш Шапиро (күптән түгел генә цех мастерлыгы хезмәтенә күтәрелде), Лунинец станциясе депосының эшчесе иптәш Детваловский һәм башка иптәшләр бар. Хезмәт ияләре сайлау комиссияләренә үзләренең иң яхшы вәкилләреннән 189 кешене җибәрделәр. Алар арасында 37 хатын-кыз бар.

МЕДИНСТИТУТНЫҢ ЮБИЛЕЙ КӨННӘРЕ

28 нче гыйнварда Кызыл Армия йортында Казан Дәүләт Медицина Институтының 125 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды.

Җыелышны фәннең атказанган эшлеклесе, Мединститут директорының урынбасары, профессор А. Н. Миславский ача. Иптәш Миславский үзенең кыска гына речендә институтның үткән тарихи юлына туктала һәм бөек большевиклар партиясе җитәкчелегендә институтның тагын да яңа уңышларга ирешәчәгенә ышаныч белдерә.

Ассистент Фазлуллин такдиме буенча җыелыш президиумына барлыгы 69 кеше сайлана. Алар арасында Алемасов, Динмөхәмәтов, Долотказин, Бычков, Шәмсеева, Гинзбург, Нежданов, Советлар Союзы Геройлары Батыршин, Чернопятко, фәннең атказанган эшлеклеләре профессорлар Трутнев, Вишневский, фәннәр Академиясенең член-корреспонденты Лаврентьев, Академик Сперанский, профессорлардан Милословский, Соколов, Новиков, Менщиков, Горяев, Терегулов, Ульянов һәм башка иптәшләр бар.

Почетлы президиумга сайлау турында профессор Ульяновның такдимен зал көчле алкышлар белән каршылый.

— СТАЛИН!

Залда күтәренкелек. Бөек юлбашчы хөрмәтенә, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре хөрмәтенә көчле алкышлар яңгырый. Почетлы президиумга бөек Сталин һәм аның иң якын көрәштәшләреннән: Молотов, Ворошилов, Калинин, Каганович, Андреев, Жданов, Микоян, Хрущев, Берия, Шверник, һәм башка иптәшләр сайланалар. Тантаналы җыелышның почетлы председателе итеп иптәш Сталин сайлана.

Медицина институтының 125 еллыгы турында доклад өчен сүз, институтның директоры иптәш Неждановка бирелә. Ул үткән тарихи юл һәм хәзерге эш турында яхшы һәм тулы доклад ясый.

Докладтан соң профессор Ульянов институт исеменә килгән күп сандагы телеграммаларны укый.

Фәннең атказанган эшлеклесе, СССР Верховный Советы депутаты профессор В. К. Трутнев СССР һәм РСФСР Наркомздравлары исеменнән институтны аның гүзәл еллыгы белән котлый. Фәннең атказанган эшлеклесе профессор Руфанов институтның 125 еллыгы уңае белән СССР һәм РСФСР Наркомздравларының приказын укый. Приказда совет медицинасы фәнен үстерүдә Казан Медицина Институтының ирешкән гаять зур уңышлары күрсәтелә һәм институтның профессор, укытучылар коллективына рәхмәт белдерелә, аеруча яхшы эш үрнәкләре күрсәткән иптәшләр бүләкләнәләр.

Аннары, юбилярне фәннәр Академиясенең член-корреспонденты, фәннең атказанган эшлеклесе профессор Лаврентьев, фәннең атказанган эшлеклесе профессор Вишневский, Иваново мединститут директоры, профессор Якобсон, Башкыртстан мединституты директоры Чубуков һәм башкалар котлыйлар.

Тантаналы җыелыш И. В. Сталин һәм В. М. Молотов иптәшләргә котлау хатын гаять зур күтәренкелек белән кабул итә.

Кичә юбилейгә багышланган пленум утырышлары башланды. Алар 2 нче февральгә кадәр дәвам итәчәкләр.

ГАВАС АГЕНТЛЫГЫНЫҢ ЯҢА ЯЛГАНЫ

ТАСС НЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

Советлар Союзына каршы яла уйдырмалары белән яшәүче Франция Гавас агентлыгы менә берничә көннән бирле инде СССР га яла яга торган яңа уйдырма тарата. Гавас агентлыгы, „Көнчыгыш Галициядә", ягни Советның Көнбатыш Украинасында, совет гаскәрләреннән тыш, имештер, бу районда „тимер юлларга контроль ясый торган" герман гаскәрләре бар, герман гаскәрләренең саны имештер, „500 кешедән 25 дивизиягә кадәр" тирбәлә, дип оятсыз рәвештә ышандырмакчы була. Бу хәбәрнең чиктән тыш кабахәт һәм ачыктан-ачык ялган булуына карамастан, ТАСС, җаваплы даирәләрнең тапшыруы буенча, шулай да Гавасның бу хәбәрен юкка чыгарырга кирәк дип саный һәм Көнбатыш Украина территориясендә бер генә чит ил солдаты яки офицеры да булмады һәм юк икәнлекне белдерә, бигрәк тә, СССР белән Германия арасында дусларча күршелек мөнәсәбәтләре бер якның нинди дә булса гаскәри частьләренең икенче як территориясендә булулары мөмкинлеген калдырмый.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

28 нче гыйнварда фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә

Иптәш Ерашов речennән

(Минзәлә районы җир бүлеге агрономы)

„Язгы чәчүгә хәзерлек турында“ ВКП(б) Өлкә Комитетының гыйнвар пленумы, безгә авыл хуҗалыгы өлкәсендә ил алдына партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан куелган гаять зур бурычларны уңышлы хәл итүгә нык ярдәм итәрлек конкрет күрсәтмәләр бирде.

Безнең Минзәлә районындагы барлык колхозларда да ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумының бу күрсәтмәләре өйрәнелә, язгы чәчүгә хәзерлек эшләре көннән-көн җәелә бара.

„Кызыл Йолдыз“ колхозында пленум күрсәтмәләрен өйрәнү өчен колхозчыларның гомуми җыелышы үткәрелгәннән соң икенче көнне үк эш сизелерлек дәрәҗәдә яхшырды. Колхоз председателе иптәш Шәмсеттинов бригадаларда даими звенолар оештыру эшенә кереште. Звенолар оештыру язгы чәчүгә хәзерлектә зур нәтиҗәләр бирде. Колхозчылар арасында хезмәт дисциплинасы элеккегә чагыштырганда шактый ныгыды. Киңәшмә үткәрелгәннән соң бу колхозда ике көн эчендә генә дә басуга 2.000 поттан артык тирес чыгарылды һәм кар тоту планы арттырып үтәлде.

Югары иген уңышы өчен көрәштә авыл хуҗалыгы белгечләре өстенә җаваплы һәм почетлы эш йөкләтелгән. Белгечләргә карата партия һәм хөкүмәт тарафыннан зур кайгыртучанлык күрсәтелүгә дә карамастан, без белгечләр, турыдан-туры әйтергә кирәк, еш кына вакытта начар эшлибез әле. Белгечләр үзләренең эшләрен тамрыннан ук үзгәртеп оештырырга тиешләр. Алар хәзер, барыннан да элек, производство белән турыдан-туры кызыксынырга, производствога эшкә барырга тиешләр. Чөнки колхозларда без белгечләргә ихтияҗ бик көчле. Колхозлар без белгечләрдән югары иген уңышы өчен көрәштә конкрет булышлык көтәләр. Ләкин безнең Татарстан АССР да Татнаркомземнан һәм төрле фәнни-тикшеренү учреждениеләреннән белгечләрне производствога җибәрү башланмаган дип әйтерлек. Бу мәсьәлә буенча Татнаркомзем һаман да әле практик эш эшләгәне юк. Татнаркомземда производствога китәргә тиешле белгечләр шактый күп. Ләкин аннан әле бары бер генә агроном производствога киткән.

Безнең Минзәлә районында да кайбер агрономнарның колхоз производствосыннан читләшүләре бар. Мәсәлән, агроном Чуковин производствога барудан баш тарта, мәктәптә немец теле укыту белән шөгыльләнә.

Соңгы вакытларда Минзәлә районында агрономнар арасында эш алып бару шактый яхшырды. Безнең барлык агрономнарыбыз дип әйтерлек ВКП(б) тарихын зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Кайбер иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне тәмамладылар да инде. Шул ук вакытта агрономнар үзләренең квалификацияләрен күтәрү белән дә шөгыльләнәләр. ВКП(б) ның район комитеты янындагы парткабинетта белгечләр һәм партия активы өчен фәнни-техник конференцияләр оештырыла. Шуның өстенә МТС янында участкы агрономнары өчен системалы рәвештә семинарлар үткәрелеп килә. Участкы агрономнары шул семинарларда алган күрсәтмәләр буенча колхозларда агрономия түгәрәкләренең эшләрен планлаштыралар һәм аларга җитәкчелек итәләр. Агрономия түгәрәкләреннән тыш без быел колхоз кладовщиклары өчен дә аерым курслар үткәрдек. 12 колхозда стахановчылар мәктәпләре оештырдык. Бу мәктәпләргә агрономнар җитәкчелек итәләр һәм шулай ук анда стахановчылар үзләре төрле темаларга докладлар ясыйлар. Мәсәлән, Минзәлә колхозының хата-лаборатория мөдире иптәш Кукаркин орлыкларны яровойлаштыру буенча үзенең тәҗрибәләре турында лекция укыды. Бакчачылык эше буенча иптәш Костин да уңышлы гына доклад ясады.

Без быел орлыкларны яровойлаштырган вакытта саф су урнына тирес сыекчасын да кулланырга уйлыйбыз. Чөнки без моның зур файда бирүен соңгы елгы тәҗрибәләрдә күреп үттек. Шулай ук җир ашлау өчен елга юшкынынан да файдаланырга уйлыйбыз.

Без быел колхозлардагы туфрак карталарыннан файдаланып туфракның төренә карап, ефремовчы звенолар һәм бригадалар өчен аерым агрономия кагыйдәләре төзибез. Без ефремовчы 11 звено өчен шундый кагыйдәләрне төзедек инде. Ул кагыйдәләрне стахановчылар белән берлектә тикшердек. Белгечләр тарафыннан күрсәтелгән бу инициативаны барлык колхозларда да бик яхшы каршы алдылар.

Без үзебезнең практик эшебездә метеорология станцияләре мәглүматларыннан киң күләмдә файдаланабыз һәм үзебездә төрле фәнни-тикшерү эшләре алып барабыз. Мәсәлән, соңгы көннәрдә уҗымнарның кар астында ничек торышларын тикшердек. Бу тикшерү, кар тоту үткәрелеп, карның калынлыгы 40 сантиметр булган участкыларда туфракта температураның минус 11 градус булуын күрсәтте. Бу температура уҗымнарның яхшы саклануы өчен тәмам канәгатьләнерлек. Үткән елны кайбер участкыларда, бигрәк тә кар тоту үткәрелмәгән участкыларда, бу вакытта уҗымнарның 60 процентка якыны суыктан һәлак булган иде инде. Ә быел без тикшергән участкыларда һәлак булу процентының 3—5 проценттан артмавын күрдек.

Агрономия чаралары комплексын үткәреп һәм хезмәтне дөрес оештырып без бөртекле культураларның һәр гектарыннан быел кимендә 100 пот иген уңышы алуга һич шиксез ирешәчәкбез. Гектарыннан 100 пот иген уңышы алуга безнең ышанычыбыз зур һәм тәҗрибәләребез дә бар. Мәсәлән, 1937 нче елны ук инде безнең „Кызыл Таң“ колхозы бригадиры иптәш Сөләйманов ике гектар мәйданда 240 пот уңыш алды. Минзәлә колхозы хаталабораториясе дә шул ук елны үзенең тәҗрибә участкыларында һәр гектардан 200 пот иген уңышы алуга иреште.

Күп кенә эшләрдә Татнаркомземның безгә җитәкчелек итүе һич тә канәгатьләнерлек түгел әле. Мәсәлән, үткән елны без орлык хуҗалыклары өчен сортлы орлыкларны, Татнаркомземның борыла алмаучылык күрсәтүе аркасында, тик 20 нче майда гына алдык. Шулай ук клевер орлыгы да бик кичегеп килде. Нәтиҗәдә аның бер өлеше бөтенләй файдаланылмый калды. Чәчү әйләнешләре һәм үлән чәчүлекләрен районлаштыру буенча фәнни-тикшеренү учреждениеләре тарафыннан да безгә хәзергә кадәр конкрет рецепт бирелгәне юк.

Урыннарга җитәкчелек итүдә мондый кимчелекләр, һич шиксез, кичекмәстән бетерелергә тиеш.

Иптәш Җәббаров речennән

(Әтнә районы, Ленин исмендәге колхоз бригадиры)

Иптәшләр! ВКП(б) ның XVIII нче съезды социалистик авыл хуҗалыгы алдына гаять зур бурычлар куйды. Сталинчыл өченче бишьеллык ахрына без һәр елны 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешергә тиешбез.

Ленин исмендәге колхоз членнары, шул исәптән минем бригада, партиябезнең XVIII нче съездының тарихи карарларын тормышка ашыру өчен ныклы көрәш җәелдерделәр. Минем бригадам бөртекле ашлыклар буенча 1937—1938 нче елларда һәрбер гектардан уртача 15,9 центнер уңыш алды. 1939 нчы елда, һава шартлары беркадәр начар булуга карамастан, минем бригадам бөртекле ашлыклар буенча һәр гектардан уртача 14,32 центнер уңыш алуга иреште.

Безнең бригада югары уңыш алуга ничек иреште соң? Без бу уңышларга агротехника чаралары комплексын тулысынча тормышка ашыру нәтиҗәсендә ирештек. Барыннан да элек, бездә туфракны тирән итеп эшләү, кар тоту планын тулысынча үтәү, җирле һәм минераль ашламаларны максимум туплау, аларны дөрес һәм үз вактында куллану, чәчүлекләрне тәрбияләү эшләре үрнәк рәвештә куелган. Чүп үләннәре чыга башлау белән үк, без аларны утадык. Шунлыктан, безнең басуларда чүп үләннәре һич тә булмады. Бездә барлык колхозчылар да ярышып эшлиләр. Чәчү һәм урып-җыю эшләре вактында системалы рәвештә стена газеталары чыгардык.

Мин үткән елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнаштым. Бу күргәзмә минем өчен зур мәктәп булды. Анда төрле өлкәләрдәге һәм республикалардагы авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәләре белән таныштым.

Мин, ефремовчы звеноларның тәҗрибәләрен өйрәнү өчен ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты тарафыннан оештырылган махсус бригада составында, Алтай краена бардым һәм Белоглазов районының „Беренче Май“ колхозында булдым. Анда, гектарыннан 70 центнер бодай уңышы алган иптәш Чуманов звеносының эш методы белән ныклап таныштым. Иптәш Чуманов үзенең участкысында җирле һәм минераль ашламаларны киң кулланган, тирес чыгарган. Шулай ук көл, фекал, сарык тизәге кебек ашламаларны да киң кулланган. Орлыкны 7 сантиметр тирәнлеккә күмдереп чәчкән. Иптәш Чуманов звеносында һәрбер квадрат метрга 500—600 орлык хисабыннан чәчәләр. Бу, центнерга күнереп исәпләгәндә, бер гектарга 2,5—3 центнер була. Алар бу орлыкларны шахмат тәртибендә, 50 процентын буйга, 50 процентын аркылыга чәчкәннәр.

Иптәш Чуманов звеносы участкысында игеннәрне тукландыру эше киң күләмдә алып барыла. Алар игеннәрне 3 тапкыр тукландыралар. Беренче тапкыр тукландыру игеннәр тишелеп чыкканда, икенчесе—игеннең тармаклануы алдыннан, өченчесе—игеннең тармаклануы вактында үткәрелә. Кагыйдә буларак, анда орлыклар һәр вакыт яровойлаштырылып чәчелә, яхшы итеп тазартыла.

Без Татарстан республикасы шартларында бу чараларны тормышка ашыра алабызмы һәм Алтай краендагы ефремовчылар звеносы ирешкән югары уңышны ала алабызмы? Бу, һич шиксез, һәрбер колхоз ирешә алырлык. Бары тик моның өчен Алтай краендагы ефремовчылар звеносы шикелле тырышып эшләргә генә кирәк.

Югары уңыш яулап алу эшендә, барыннан да элек, даими звенолар оештыру гаять зур урын тота. Бу звенолар практикада үзләрен тулысынча акладылар һәм алар Советлар Союзының барлык өлкәләрендә һәм республикаларында көннән-көн арталар.

Алтай краеннан алып кайткан бу тәҗрибәләрне мин үземнең бригадамда һәм колхозда тормышка ашырырмын. 1940 нчы елда иң элек бригадамда ефремовчы звенолар оештыруны, звеноларның һәрберсенә 3 әр гектар күләмендә участкылар бүлеп бирүне һәм бу участкыларның һәр гектарыннан уртача 50—60 центнер уңыш алуны бурыч итеп куйдым. Бу бурычны үтәү өчен мин хәзер бөтен рессурсларны туплыйм, ашламалар җыям, кар тоту һәм башка чараларны үткәрәм. Моннан тыш мин 20 гектар мәйданда һәрбер гектардан 22 центнер бодай уңышы алуны планлаштырам һәм үземнең бригадама беркетелгән участкының һәрбер гектарыннан уртача 16—17 центнер уңыш алуны йөкләмә ител алам. Авыл хуҗалыгының барлык алдынгыларын миннән үрнәк алырга чакырам. (Кул чабулар).

Иптәш Жарков речennән

(Чувашстан АССР ның, Вурнар районы, Сталин исмендәге колхоз председателе)



Иптәшләр! Чувашстан республикасының Вурнар районы, Сталин исмендәге колхоз членнары исменнән Сезгә большевистик ялкынлы сәлам! (Кул чабулар).

Иптәшләр! Мин бу киңәшмәдә безнең Кольцовка авылының элекке һәм хәзерге хәленә тукталмакчы булам. Революциягә кадәр Кольцовка иң артта калган, надан авылларның берсе иде. Анда бер нинди мәктәп тә юк иде һәм авылның бер генә кешесе дә укый-яза белми иде.

Коммунистлар партиясенең һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталинның җитәкчелеге һәм хезмәт иясе крестьяннар турында өзлексез кайгыртучанлык күрсәтүләре нәтиҗәсендә безнең авыл танымаслык булып үзгәрде.

Колхоз төзелеше Кольцовка авылы крестьяннәренә бетмәс-төкәнмәс көч бирде. Безнең колхоз 11 ел эчендә иген уңышын күтәрүдә дә, терлекчелекне үстерүдә дә һәм культура өлкәсендә дә гаять зур уңышларга иреште. Колхозчылар иптәш Сталинның колхозларны большевистик, колхозчыларны культуралы таза тормышлы итү турындагы күрсәтмәсен намус белән үтиләр.

Без бу чор эчендә, үзебезнең көчебез белән, колхоз средстволарына 10 еллык мәктәп, 500 кеше сыешлы клуб салдык. Безнең колхозның тавышлы киносы һәм радио узелы бар. Ул барлык колхозчы йортларына хезмәт күрсәтә. Шулай ук без электр-станция, 10 мең сумлык җиһазлары белән хата-лаборатория, бала тудыру йорты, медицина һәм ветеринария пунктлары төзедек.

Колхоз төзелгәч, 127 колхозчы үз хуҗалыкларында 6 шар почмаклы өй салдылар. Хәзер бездә укый-яза белмәүчелек тулысынча бетерелде.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турындагы карарында һәрбер колхозда кимендә 2 ферма булдыру бурычын куйдылар. Безнең колхоз бу күрсәтмәне арттырып үтәде. Товарлыклы сөтчелек фермабызда 110 сыер бар. 100 баш дуңгызны эченә алган ит фермасы һәм 100 баш сарыктан торган сарык асраучылык фермасы бар. Бу, икенче төрле әйткәндә, колхоздагы җир мәйданына карата бирелгән план 120 процент үтәлгән диган сүз. 200 хуҗалыклы бөтен авылга 60 сыер булган булса, хәзер сыерсыз бер генә колхозчы да юк.

Совет власте төзелгәннән соң, бигрәк тә колхоз төзелешеннән соң, безнең авылдан бик күп кадрлар—партия һәм совет оешмаларында эшләүче работниклар, белгечләр үсеп чыктылар. Безнең хәзер үзебезнең медицина фельдшерыбыз, ветеринария фельдшерыбыз, агрономыбыз, механигыбыз, радистыбыз һ. б. бар. Болар барсы да партиябез һәм хөкүмәтебез җитәкчелегендә тәрбияләнеп үскән, колхоз авылы үстергән яңа кешеләр.

Безнең колхоз 1937 нче елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 29,9 центнер, 1938 нче елда—17 шәр центнер уңыш алды һәм Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашты. Югары иген уңышы алуга ирешүе өчен, терлекчелек эшен үрнәк булырлык итеп оештыруы өчен Күргәзмәнең Баш Комитеты колхозыбызны беренче дәрәҗә диплом, 10 мең сум акча һәм җиңел автомашина белән бүләкләде. 1939 нчы елгы күрсәткечләребез дә түбән түгел. Һәр гектардан уртача 13 центнер бөртекле иген уңышы алдык. Колхозчыларның һәр хезмәт көненә 1937 нче елда 13,5 килограмм ашлык һәм берәр сум акча, 1938 нче елда—6,5 килограмм ашлык һәм 1939 нчы елда—3,5 килограмм ашлык һәм 1 сум акча, 3 әр килограмм яшелчә бүлдек.

Тагын да югары, ныклы иген уңышы алу өчен безнең колхозчылар нинди бурыч куйдылар?

Безнең колхоз членнары быел 700 гектар чәчү мәйданының һәр гектарыннан уртача 200 пот иген уңышы алу бурычын куйдылар. Моңа ирешү өчен, йөкләмәбез буш сүз булып калмасын өчен нәрсә эшләдек һәм нәрсә эшлибез? Язгы чәчүгә кирәкле барлык орлыклар беренче класслы итеп хәзерләнгән. Алар коры урында сакланалар. Орлыклык участкыларга чәчеләчәк орлыкларны кул белән чүпләп сортладык. Авыл хуҗалыгы машиналары тулы хәзерлектә.

Югары уңыш алу—гади эш түгел. Аны яулап алырга кирәк. Ә моның өчен, барыннан да элек, хәзерлекле кадрларның булуы таләп ителә. Без агротехниканы өйрәнү буенча колхозчыларның кичке укуын оештырдык. Анда сабанчылар, чәчүчеләр, звено башлыклары, яровойлаштыручылар, колхоз активистлары—барлыгы 160 кеше укый.

Агротехника чараларын үткәрү буенча конкрет планыбыз бар. Без быел 160 мең сумлык азотлы, калилы һәм фосфорлы ашламалар сатып алабыз. Моның өчен дәүләт безгә 130 мең сум кредит бирде. Шулай итеп, быел басуга 7.647 тонна минераль ашламалар кертәчәкбез. Колхоз 1940 нчы елда чәчүлекләрне сугару өчен машина сатып алуны планлаштырды.

Иптәшләр, без бер урында таптанып тора алмыйбыз, гектардан 100 пот уңыш безнең өчен чик була алмый. Без инде югары уңышны тәҗрибә участкыларында гына түгел, барлык чәчү мәйданыннан да алуны тәэмин итәргә тиешбез. Моның өчен безнең илдә чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Тик ул мөмкинлекләрдән оста итеп файдалануны оештырырга, намус белән эшләргә кирәк. Шулай эшләгәндә без, һич шиксез, 8 миллиард пот ашлык җитештерү турында иптәш Сталин тарафыннан куелган бурычны уңышлы үтәячәкбез һәм үтәрбез!

Яшәсен безнең даһи юлбашчыбыз иптәш Сталин! (Көчле кул чабулар).

Иптәш Хафизов речennән

(Буденный районының „Гигант № 2“ колхозы агротехнигы)

Иң якындагы 3—4 ел эчендә һәр ел саен 8 миллиард пот уңыш алу турында иптәш Сталин күрсәтмәсен һәм Сталинград өлкәсе алдынгыларының һәрбер гектардан 100 пот уңыш алуга чакыруларын безнең колхозчыларыбыз һәм колхозчы хатын-кызларыбыз гаять зур күтәренкелек белән каршыладылар.

Безнең колхоз язгы чәчүгә зур хәзерлек алып бара. Быел колхоз 2.000 гектар җиргә чәчү үткәрергә тиеш. Моның өчен кирәк булган орлык 100 проценты белән хәзерләнде. Орлыкның 90 проценты кондециягә китерелгән. 2.000 гектар мәйданда кар тотылды. 3.000 йөк тирес чыгару планының 60 проценты инде үтәлде. Авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау төгәлләнде һәм алар бригадирларга акт буенча тапшырылдылар. Колхозның атлары язгы чәчүгә хәзер. Аларга кышкы көннәр һәм язгы чәчү вакытлары өчен җитәрлек фураж булдырылды.

Колхозда агротехника укулары киң җәелде. Агротехниканы өйрәнү түгәрәкләренә 450 кеше тартылган. Түгәрәкләрнең 20 занятиесе үткәрелде. Моннан тыш, стахановчылар мәктәбендә 31 кеше укый. Хатын-кызлардан 21 кеше тракторчылар хәзерләү курсына йөри.

Колхозларда бөртекле культураларны чәчүне планлаштыру тәртибе турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм Совнарком карарын безнен колхозчыларыбыз зур шатлык белән каршы алдылар һәм 1940 нчы елда бөртекле культуралар чәчү планын тикшерүдә актив катнаштылар. Бу планны тикшергәндә бригадалар үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар һәм һәрбер гектардан 100 пот уңыш алу өчен үзара социалистик ярыш договорлары төзеделәр. Безнең колхоз „Ирек“ колхозы белән ярыш договоры төзеде.

Дөрес, „Гигант № 2“ колхозы үткән елны һәрбер гектардан уртача 11 центнер гына уңыш алды. Ләкин, кайбер бригадалар, мәсәлән 7 нче бригада, гектардан 12 центнер бодай уңышы алды.

Мин 1938 нче елны бодайның аерым эре башакларын җыеп, барлыгы 15 килограмм орлык җиган идем. 1939 нчы елны мин аларны 0,33 гектар җиргә чәчеп, барлыгы 9 центнер 72 килограмм уңыш алдым. Моны мин тәҗрибә өчен эшләдем һәм агрономиянең барлык чараларын кулландым.

Колхозда 1937 нче елдан бирле хата-лаборатория яхшы гына эшләп килә. Һәрбер культураның экспонатлары шушында сакланалар. Лаборатория 250 гә якын төрле чүп үләннәре җыйды. Лабораториянең эшенә—лаборатория янында агротехника укуларын оештыруда Казан селекция станциясенең агрономы иптәш Аитов күп ярдәм итә.

Без терлекчелек өлкәсендә артка калмыйбыз. Сарык асраучылык фермасы үткән елны 100 баш сарыктан 149 баш бәрән үстерде һәм шуның өчен колхоз Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашып, II нче дәрәҗәле диплом, мотоцикл һәм 5.000 сум акча белән бүләкләнде. Без—мин һәм ферма мөдире иптәш Миңлебаев 1940 нчы елда 100 баш сарыктан 160 бәрән үстерергә сүз бирәбез. (Кул чабулар).

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының киңәшмәсендә. РӘСЕМДӘ: хатын-кыз делегатларыннан бер төркем. Алда утыралар (сулдан)—Р. Диярова (Лөбъяз), Н. Закирова (Саба), артта (сулдан)—Н. Вәлиева, З. Хәйреттинова (Азнакай) һәм Кайбыч районыннан М. Хәйреттинова иптәшләр.

М. Солтанов фотосы.

ЮГАРЫ УҢЫШ МАСТЕРЛАРЫ

ЯРЫШЫП ЭШЛӘҮ НӘТИҖӘСЕ

Югары уңыш алу һәм терлекчелекне үстерү өчен безнең колхоз үткән ел Биектау районының Молотов исемендәге колхоз белән ярышкан иде. Без аны быел да ярышка чакырабыз. Шулай ук йөзпотчыларның Бөтенсоюз ярышына да кушылдык.

Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм эшнең югары сыйфаты өчен көрәштә социалистик ярышның зур роль уйнаганлыгын колхозчылар яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә бездә ярышка кушылмаган кеше юк.

Минем бригада иптәш Уколов бригадасы белән ярышты. Һәрбер колхозчы ярыш дулкыны белән чолгап алынды. Сөрүчеләр, чәчүчеләр, көлтә бәйләүчеләр үзара ярышып эшләделәр. Ярыш нәтиҗәләре колхозның стена газетасында системалы рәвештә яктыртылды. Колхоз стахановчыларының данлыклы исемнәре кызыл тактага бер-бер артлы язылып торды.

Бездә югары хезмәт җитештерүчәнлеге, эшнең югары сыйфаты өчен бирелеп көрәшкән һәм күп тапкыр бүләкләнгән Александр Рязанов, Михаил Комиссаров, Василий Рязанов, Дмитрий Гаврилов, Татьяна Феофанова, Николай Алексеев, Евдокия Рязанова, Анна Уколова, Егор Мухаричев, Мария Никишина кебек дистәләрчә стахановчылар бар.

Колхоз производствосының шундый командирлары булган һәм ярыш байрагын югары күтәргән колхозда югары уңышка ирешү гаҗәп түгел.

Молотов исемендәге колхоз белән ярышта без җиңеп чыктык. Үз эшебезне иң кыска срокларда югары сыйфатлы итеп тәгәлләү белән бергә, урып-җыю эшләрендә без „На страже“ һәм „12 лет Октября“ колхозларына социалистик булышлык күрсәттек.

Бригадалар ярышында минем бригада өстен чыкты. Иптәш Уколов бригадасы бодай уңышын һәр гектардан уртача 12, 68, солы уңышын 12, 61 центнер алган булса, минем бригада бодай уңышын 18, солы уңышын 19 центнер алды. Уколов бригадасының чәчү мәйданы минем бригаданыкыннан 4 гектарга артык иде. Шулай да, минем бригада уңышны 557 центнер артыграк алды.

Производство планы—колхоз эшенең көзгесе. Производство планнарын без колхоздагы бөтен мөмкинлекләрне исәпкә алу нигезендә төзибез. Бу эшкә агротехник, бригадирлар, тәҗрибәле колхозчылар, стахановчылар актив катнашалар. Производство планы колхозчыларның гомуми җыелышында, ә бригадаларның эш планнары бригада җыелышларында тикшерелеп, аларга үзгәртмәләр һәм өстәмәләр кертелә. Шуңа күрә безнең планнар реаль булып чыгалар, тормышка тулысынча ашырылалар.

Югары уңышны яулап алу өчен агротехника чаралары комплексын дөрес үткәрергә, югары сыйфатлы итеп башкарып чыгарга кирәк. Без шулай эшлибез дә.

Минем бригада пар җирләренең бер участкысын тирес белән, икенче участкысын яртылаш фосфорит оны аралаштырылган тирес белән ашлау тәҗрибәсен үткәргән иде. Кушылган ашлама яхшы нәтиҗә бирде. Агуланган, яровойлаштырылган, кондициягә җиткерелгән орлыклар чәчәргә, чәчү өчен туфракны яхшы хәзерләргә, җирнең дымлылыгын югалтмаска, иген кырларында чүп үләннәре үсүенә ирек бирмәскә, кыр эшләрен иртә һәм иң кыска срокларда үткәрергә. Югары иген уңышы алуның сере әнә шунда.

Стахановча методлар белән эшләү нигезендә, без югары уңыш яулап алдык. Колхозчылар хезмәт көннәренә мул уңыш алдылар. Без быел тагын да югарырак уңыш өчен көрәшәбез, һәм моңа ирешербез. Ефремовчылар һәм йөзпотчылар югары уңыш өчен көрәшнең әлегә кадәр күрелмәгән үрнәкләрен бирделәр. Алар юлы белән барып, тагын да югарырак уңыш алу—безнең алда сугышчан бурыч булып тора.

Минем бригадада ефремовчылар звеносы төзелде. Стахановчы Василий Рязанов звеновод итеп билгеләнде. Звено алдына бодай һәм солы буенча һәр гектардан уртача 30 центнер, бәрәңге буенча 150 центнер уңыш алуга ирешү бурычы куелды. Ефремовчылар хәрәкәте турында үткәрелгән киңәшмәдә чыгып сөйләгән колхозчылар югары уңыш өчен ефремовчыларча көрәшергә, былтыргыдан яхшырак эшләргә сүз бирделәр.

М. Я. Еремин.

Буденный исемендәге колхозның 2 нче бригадасы бригадиры.

Биектау районы, Буденный исемендәге колхозның алдынгылары. РӘСЕМДӘ: беренче рәттә (сулдан уңга) М. Т. Никишина (яшелчәчелек бригадасының звено башлыгы), М. И. Комиссаров, Н. С. Алексеев. Икенче рәттә: Д. Б. Гаврилов (ат караучы), И. С. Морозов (агротехник), А. Ф. Уколова иптәшләр. И. Галиев фотосы.

ЯШЕЛЧӘДӘН 86.500 СУМ ДОХОД

Яшелчәдән югары уңыш алу агротехника чараларын дөрес үткәрүгә бәйләнгән. Шунлыктан, без төп игтибарны агротехника чараларына юнәлдерәбез. Без үткән елны ничек эшләдек соң? Үткән елны 14 нче мартта тиресне кайнар су белән чылатып, иңе 3 метр, биеклеге 2 метр өемнәргә өйдек. Парникларга 13 нче апрельдә тирес, 15 нче апрельдә балчык салдык. Балчык эрегәч, 17 нче һәм 18 нче апрельдә 3 котлаванга кәбестә, бер котлаванга помидор үрентеләре утырттык. Тирес өлгереп җитмәгәнлектән, 4 котлаванга помидорны 24 нче һәм 28 нче апрельдә генә утыртырга туры килде. 5 нче майда 2 котлаванга кыяр утырттык. Майның 5 ләре тирәсендә кәбестә үрентеләрен парниклардан казылмаларга күчердек. Кәбестәдән бушаган парникларга балчык өстәп, аларга, бер-берсеннән 10 сантиметр ара калдырып, помидор үрентеләрен күчереп утырттык.

Безнең яшелчә бакчасы уйсу һәм авыр туфраклы җирдә. Шунлыктан, көчле яңгырлардан соң туфрак таш кебек ката, аны китмән белән йомшартып торырга туры килә. Шуңа күрә соң өлгерә торган кәбестә үткән елны яхшылап бөреләнә алмады, иртә өлгерә торган кәбестәгә караганда кимрәк уңыш бирде. Кәбестәләрдә кәбестә корты күренә башлаган иде. Көл сибү юлы белән кәбестә кортларын бетердек.

Без үткән елны парниклардан башка 8,5 гектар мәйданда кәбестә, помидор, кыяр, кишер һәм суган утырткан идек: Туфракның төзелеше яшелчәләр өчен бик үк яраклы булмавына карамастан, күрше колхозлар белән чагыштырганда, шактый югары уңыш алдык. Иртә өлгерә торган кәбестә һәм кыяр сатудан колхоз акчалата 86.500 сум доход алды. Шуның өстенә колхозчыларның һәр хезмәт көненә 7,5 килограмм яшелчә бүлеп бирелде.

Яшелчә бригадасындагы колхозчыларның барсы да ярышып эшләделәр. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм югары сыйфат өчен көрәш үрнәге күрсәткән стахановчылардан Мария Алексеева һәм Мария Никишина иптәшләр бүләкләнделәр.

Яшелчәләрдән тагын да югарырак уңыш алу өчен без язга хәзерлек эшләрен җәелдердек. Казылмалардагы туфракны өемнәргә өеп куйдык. Аланнан яңа туфрак ташып һәм иләп өеп куйдык. Бу туфракны парникларга салачакбыз. Яшелчә бакчасына тирес ташып, өемнәргә өеп куелды.

А. И. Аристова.

Биектау районы, Буденный исемендәге колхозның яшелчәчелек бригадасы бригадиры.

БЕЗНЕҢ ТӘҖРИБӘ

— Бер үк һава шартларында эшләдек, туфрак төзелеше ягыннан да әллә ни аерма юк, ничек соң сезнең колхоз безнекеннән югары уңыш алды?—дип сорыйлар күрше тирәдәге колхозлардан килүчеләр.

Чыннан да, безнең уңыш күп кенә колхозлар өчен сокланырлык. Безнең җиңүләр нигезендә стахановча эшләү методларын киң куллану һәм агротехника чаралары комплексын дөрес үткәрү ята. Җирнең уңдыру көчен арттыру өчен без җирле ашламалардан тулы файдаланабыз. 1938 нче елны май азагында һәм июнь башында басуга 3.800 йөк тирес чыгарып, 25 гектар җирне тиресләдек. Яшелчә бакчасына да 1.500 йөк тирес керттек. Хезмәт бушка китмәде: тиресләгән җирләрдә иген котырып уңды.

Ни чәчсәң, шуны урырсың,—дип, картлар белми әйтмәгәннәр. Чүпле, ач орлык чәчеп, югары уңыш көтеп булмый. Шуңа күрә чәчү орлыкларының сыйфатына аеруча зур игтибар бирәбез. Орлыклык участкыларга берничә тапкыр триер аша үткәрелгән иң югары сыйфатлы орлыклар чәчәбез. Колхозның электростанциясенә корылган моторлар ашлык сугу машиналарына тоташалар. Машиналарның берсе дәүләткә тапшырыла торган ашлыкларны, ә икенчесе көзге чәчү өчен кирәкле ашлыкларны суга. Машинадан чыгу белән орлыклар триер аша үткәреләләр. Элек орлыклар агуланмый чәчелгәнлектән, игеннәрне гөмбә авыруы баса иде. Хәзер аны бөтенләй җиңдек диергә була. Арышны Давидов припараты белән, ә бодай орлыгын термик ысул белән агуладык.

Кар тоту җирнең дымлылыгын арттыруда, корылыкка каршы көрәштә зур роль уйный. Шуңа күрә без 250 гектар мәйданда 40—50, урны-урны белән 70—80 сантиметр калынлыкта кар тоттык. Әлегә кадәр щитлар өчен материаллар җитешмәве кар тоту эшен киң колач белән алып баруга комачаулый иде. Ефремовчылар тәҗрибәсеннән файдаланып, быел без кар өемнәре ясап, кар белән кар тоту методын куллана башладык. Моның өчен тактадан махсус ящикләр эшләдек. Алар белән ат җигеп эшләнә. Бу ящикләрнең кар сабаныннан аермасы шунда: кар сабаны карны икегә аерып, тоташ вал ясап бара, ә бу ящикләр карны өем-өем итеп ташлап калдыра баралар.

Орлыклык участкылардагы 10 гектар арыш һәм 5 гектар көзге бодай чәчүлекләрен суперфосфат белән тукландырдык.

Чүп үләннәре—игеннәрнең дошманы. Алар игеннәргә иркенләп үсәргә ирек бирмиләр, һәм туфрактагы азыкны үзләренә алалар. Шуңа күрә без чүп үләннәрен җыеп яндырабыз, чәчүлекләрдәге чүп үләннәрен калдырмый утыйбыз.

Язгы чәчүне без бик яхшы хәзерлек белән үткәрдек. Чәчү орлыкларын формалин, тукранбашны Давидов препараты белән агуладык. Орлыклык участкыга чәчелгән „Капитал“ борчагын нитрагинлаштырдык.

Орлыкның тизрәк тишелеп чыгуында һәм игеннәрнең иртә өлгерүендә яровойлаштыруның нинди зур роль уйнаганлыгын тәҗрибә ачык күрсәтте. Туңга сөрелгән җирләрдә туфракны хәзерләгән арада без чәчү орлыкларын яровойлаштырабыз. Яровойлаштырылган орлык 6—7 көндә, бәрәңге бер айда өлгерә. Шуннан артык ятса, тишелеп чыккан үрендененң сынуы мөмкин.

Чәчү нормасын һәм орлыкны күмдерү тирәнлеген дөрес билгеләү—иген уңышын күтәрү өчен кирәкле шартларның берсе. Әгәр орлыкны тирән күмдерсәң, тишелеп чыга алмый, ә сай күмдерсәң, көчле яңгырдан соң җир утырса өскә калкып һәлак була. Бодайны һәр гектарга 1,6 центнер, солыны 1,5, борчакны 1,3, орлык өчен булган торна борчагын 1,5 (10 кило солы аралаштырып), печән өчен торна борчагын 1,3 центнер (30 кило солы аралаштырып) чәчеп, 5 сантиметр тирәнлектә, тарыны һәр гектарга 20 килограмм чәчеп, 1,5—2 сантиметр тирәнлектә күмдердек, „Вольтман“ сортлы бәрәңгене һәр гектарга 12 центнер, „Лорх“ сортлы бәрәңгене 9,5 центнер утыртып, рәт араларында 70, бәрәңгеләр арасында 35—40 сантиметр ара калдырдык. Бәрәңге тишелеп чыгу белән бәрәңге утыртылган җирләрне тырмаладык. Орлыклык участкыларда чүп үләннәрен генә түгел, авыру бәрәңгеләрне дә утадык.

Агротехника чараларын дөрес куллану нәтиҗәсендә бөртекле культуралар буенча һәр гектардан уртача 14,11 центнер уңыш алдык. Орлыклык участкыларда арыш уңышы уртача 14,72, көзге бодай уңышы 15,91 центнер булды. Колхозның алдынгы бригадасы (бригадиры иптәш Еремин) һәр гектардан уртача 18,7 центнер бодай, 19 центнер солы уңышы алды.

Быел тагын да югарырак уңыш алу өчен ефемовчыларның агротехника методларын киң кулланып, язгы чәчүне отлично үткәрүгә бөтен көчне куябыз.

И. С. Морозов.

Биектау районы, Буденный исемендәге колхозның агротехнигы.

СОСНОВКАДА

Без Биектау тимер юл станциясеннән карагай урманы аша үтеп, район башкарма комитетына таба барабыз. Үрәчәле чанага җигелгән кара туры ат, ярсып, чабып, безне узып китте һәм ике катлы биек йорт турына барып туктады.

— Әһә, могаен, безне алырга килгәндер,—дидек.

Зур якалы толып кигән таза гәүдәле егет чанадан җитез генә икереп төште дә, атны баганага әйләп куйды. Аннары чанадан ике олып алып райбашкармага таба атлады. Чыннан да ул безне алырга килүче булып чыкты. Без тиздән Бирюли ягына карап юл тоттык. Туры айгыр кар бураны туздырып, безне каен һәм имән катнаш нарат урманы буйлап Сосновка авылына алып китте.

Минем янда баручы, шактый сөйләшергә яратучан иптәшем, ат тотып баручы әлеге егетнең кылын тартып карыйм әле дигәндәй, хәйләкәр елмаю белән:

— Чыбыркы алырга онытқансыз ахры,—дип куйды.

Теге егет тә тапкыр икән, җавапка бер дә аптырап тормыйча:

— Без атны солы белән куабыз,—ди, үзе елмая.

Аннан ул безгә колхозның тормышы турында тезеп китте. Аның керсез күңелдән әйтелгән сүзләрендә колхозның ничек сулаганлыгы чагыла.

Әнә зур бакча эчендә шәһәрчә эшләнгән өйләр күренә. Монда элгәре алпавыт Юнусовларның хуторы булган. Бу тирәдәге меңнәрчә гектар җирләргә алпавыт Юнусовларда кол булып эшләгән крестьяннарнең маңгай тирләре аккан, күз яшьләре түгелгән. Алар менә шушы җирләрдә Юнусовларга уртакка эшләп, бөкерләрен чыгарганнар. Ни эшләсеннәр соң, уч төбедәй җир белән туеныл булмый бит. Эш эзләп шәһәргә барса, шәһәр дә якты чырай күрсәтмәгән, кая гына барса да, мохтаҗлык крестьяннең артыннан калмаган. Йөреп-йөреп тә булмагач, ул бичара әлеге шул Юнусовларга барып егылырга, тез чүгәргә мәҗбүр булган. Билгеле, уртакка эшләү шома гына үтмәгән. Алпавытның доверенныйлары, үләксә саклаган козгын кебек, игеннәрнең урылып бетүен сагалап кына йөргәннәр. Алар урылган көлтәләрнең яртысын алпавытлар ындырына ташытканнар. Кайбер йөрәклерәк крестьяннәр көлтәләрне бүлешкәндә алпавытларның доверенныйлары белән якалашканнар. Дмитрий Феофановның көлтә бүлешкән вакытта Юнусовлар доверенныйе Шаһвәли белән басуда сугышканын Сосновка авылының картлары хәтерлиләр.

Элекке алпавыт Юнусовлар хуторын—хәзерге Бирюли җәнлек совхозын узып, ике километр чамасы киткәч, юртак айгыр безне электр лампалы баганалар тезелеп киткән урам буйлап, Сосновка авылына алып керде.

— Буденный исемендәге колхоз менә шушы була инде,—диде ат куучы. Колхоз правлениесенә кереп исәнләшкәч, завхоз Мухорчев:

— Мактап йөрисез икән, туйга туры килдегез, бүген бездә колхоз стахановчылары Петр Яшин белән Матрена Новикова туе,—дип көлеп куйды. Колхозчылар бу туйны, бәйрәмгә хәзерләнгән кебек, көтеп алганнар.

Менә, таза гына гәүдәле, кара сакалына чал кергән бер карт килеп керде. Йөзендәге җыерчыклар аның күпне күргән кеше булуы турында сөйлиләр. Мин аның үткәндәге һәм бүгенге хәле белән кызыксындым.

— Ни хәл бабай, эшләр барамы?—дидем.

Бу сорауга җавабында колхоз амбарларын саклаучы Василий Рязанов:

— Майлагандай бара,—диде, башын күтәрә төшеп.

Мохтаҗлык аны унике яшеннән шәһәргә куган. Кая гына барса да, тамагы туймаган, өсте бөтәймәгән.

— Минем кебекләр безнең авылда өй саен иде,—диде ул.

Революциядән соң, алпавытлар куылгач, Василий бабай авылга кайта. Шуннан соң ул авылда гомерлеккә төпләнеп кала. Майлагандай бара,—дип, ул шаярып әйтми. Колхоз тормышында гына аның тамагы туйган, өсте бөтәйгән. Семьясе белән 942 хезмәт көне эшләп, ул 311 пот ашлык, 412 пот бәрәңге, 1.500 сумнан артык акча алган.

Кемгә генә карама, шат чырай очратасың. Бу шатлыкның нигезендә культуралы таза тормыш ята. Алпавыт Юнусовлар заманында дисәтинәсенә 30—40 поттан артык уңыш бирмәгән җирләрне колхоз производствосының командирлары югары уңыш бирергә мәҗбүр иткәннәр. Элек сука, урак, чабагач, көрәктән башка иген кораллары күрмәгән басуларда хәзер машиналар эшли. Элгәре иген уңдыру көчен югалткан басу бүген ашламалар белән тукландырыла. Колхоз тәрбияләп үстергән агротехник Морозов иген һәм яшелчә уңышын елдан—ел күтәрү өстендә эшли. Җиренә җиткереп хәзерләнгән туфракка яхшы сыйфатлы сортлы орлыклар гына чәчелә. Колхозчыларның барсы да кыр эшләрен кыска срокларда, яхшы башкарып чыгу һәм югары уңыш алу өчен көрәш дәрте белән яналар. Колхоз эшенә үз эшең итеп карагач, эшнең яхшы баруы бик табигый.

— Бездә эшкә җибәрү өчен колхозчылар артыннан чабып йөрергә туры килми. Алар үзләре эш сорап киләләр,—ди бригадир иптәш Еремин.

Әйе, алар чын күңелдән бирелеп, ярышып эшлиләр. Намус белән эшләү нәтиҗәләре күз алдында.

Буденный исемендәге колхоздан ярты километр ераклыкта гына „Гудок“ колхозы бар. Бер үк һава шартларында яшиләр. Җирләрендә дә әллә ни аерма юк. Аерма тик шунда гына, „Гудок“чыларда колхоз эшенә дәрт җитеп бетми. Алар югары уңыш өчен начар көрәшәләр, анда дисциплина йомшак. Шуңа күрә колхоз бөртекле культуралар уңышын һәр гектардан уртача 7,5 центнер гына алган.

Күрше колхозлардан Каганович исемендәге колхоз да бөртекле культуралар уңышын һәр гектардан уртача 8,5 центнер гына алган. Ә Буденный исемендәге колхоз бөртекле культуралар уңышын гектардан уртача 14,1 центнер алып, һәр хезмәт көненә 5 килодан артык ашлык, 7 кило бәрәңге, 1,5 кило яшелчә, 1 сум 50 тиен акча бүлеп биргән. Колхозчылар арасында 4—5 йөз пот ашлык, 5—6 йөз пот бәрәңге, 2.000 сумнар акча алучы семьялар байтак. Колхоз председателе иптәш Новиковның:

— Ашлык һәм бәрәңгеләрегезне ник килеп алмыйсыз,—дигән соравына колхозчылар:

— Ул кадәр ашлыкны, бәрәңгене кая куеп бетерәсең, колхоз амбарында яхшырак саклана, тора бирсен,—дип җавап кайтаралар.

Намуслы хезмәт колхозчыларны культуралы таза тормышка китергән. Ике яшь стахановчының 5—6 көнгә сузылган, колхозчыларның барсы да диярләк катнашкан туе—таза тормышның җанлы шаһите. Бу туй колхозчыларның дуслыгын, бердәмлеген дә күрсәтә. Бу туйда ызгыш, талаш, сугыш кебек элекке гадәтләрнең әсәре дә юк. Стахановчылар туе—колхоз строеның җиңү тантанасы.

Колхозчылар ирешелгән уңышлар белән мавыкмыйлар. Алар тагын да югарырак уңыш алу өчен йөзпотчылар ярышына кушылганнар. Алар, югары уңыш мастерлары булган ефремовчыларның эш методларын үзләштереп, яңадан-яңа биеклекләрне яулап алу өчен көрәшәләр. Язгы чәчүгә отлично хәзерләнәләр.

Дөрес, ефремовчылар ирешкән уңыш белән буденныйчылар уңышы арасында әлегә аерма зур. Ләкин большевиклар ала алмаган крепостьлар юк.

Еремин бригадасында төзелгән ефремовчылар звеносы—рекордлы уңыш алу өчен көрәшнең беренче карлыгачы.

Бүген бу звено бодай һәм солы уңышын һәр гектардан уртача 30 ар центнер, бәрәңге уңышын 150 центнер алуны үзенең бурычы итеп куйган булса, колхозның башка даими звенолары да шул ук юл белән югарыга үрмәләргә хәзер торалар.

Бу гүзәл хәрәкәт турында ефремовчылар белән киңәшмәдә колхозчылар:

—Ефремовчылар кебек эшләрбез, эш тә, уңыш та безнең кулдан ычкынмас,—диделәр. Алар, үткән елга караганда, быел тагын да яхшырак эшләргә сүз бирделәр. Колхозчылар бу сүзләрендә торырлар да. Әйткән сүз—алар өчен закон. Колхозның стахановчылары ефремовчылар мәктәбендә югары уңыш алуның серләрен күңел биреп өйрәнәләр.

Н. Мансуров.

Скандинавия илләре һәм Англия

СТОКГОЛЬМ, 28 гыйнвар. (ТАСС). Норвегиянең „Тиденс Тейн“ газетасы Англия белән Скандинавия илләре арасында сәүдә сөйләшүләре турында мәкалә иглан итте. Газета бу мәкаләсендә түбәндәгечә яза: „Тик бер Швеция генә Англия белән сәүдә договоры төзеде. Норвегия—Англия сөйләшүләре тупикка керде; Дания—Англия сөйләшүләре дәвам итә итүен, ләкин Дания бу сөйләшүләрнең барышы белән канәгатьләнми. Англия Төньяк илләрдә фактта клиринг исәбе билгеләп, маглүм бер маневр белән алардагы бөтен тышкы сәүдәне үзенә буйсындырырга тели. Швециянең, шундый договор төзеп, үз валютасына маневр ясау ирекслелеген югалтуы уңае белән тәәссеф белдермичә булмый. Швециянең юл куюы безнең илләрнең хәлен дә начарлатты.

Даниянең тышкы сәүдәсенең йомгаклары аның кыен хәлдә икәнлеген күрсәтәләр. Әгәр дә хәзер Англия белән булган клиринг исәпләренең яңа тәртибенә юл куйсаң, ягни, экспортның импорттан артуы өчен валюта алудан баш тартсаң — Англиядән товар кертүне арттырырга кирәк булачак. Мондый хәлнең Дания экономикасы өчен зур кыенлыклар китереп чыгарачагы табигый.

Норвегиянең Англиядән булган импорты 1938 нче елда экспорттан 55 миллион крон артык булды. Англия белән булган сәүдәдәге бу пассивны Норвегия пароходчылыктан алына торган доходлар белән каплый һәм, димәк, түләү балансы буенча Англиядән зур гына сумалар алырга тиеш була. Швециянекенә охшаган яңа тәртипне кертү Норвегия өчен бәхетсезлек булыр иде“.

Шундый шартларда,—ди газета,—Англиянең безгә дуслык хисләре белән тулган булуы турындагы белдерүләренә ышанырга мөмкинме соң!

КӨНЬЯК АФРИКА СОЮЗЫ ПАРЛАМЕНТЫНДА

БЕРЛИН, 28 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы Көньяк Африка Союзында милләтчеләр партиясе җитәкчесе Маланның парламентта, премьер Смэтсны, Англия яклы политика алып баруы өчен, кискен рәвештә тәнкыйтьләп чыкканлыгын хәбәр итә. Оппозициянең көчле рәвештә кул чабуы астында Малан: „Көньяк Африканың Европа сугышында катнашуыннан бары тик Бөек Британия белән гомумән мөнасәбәтләрне өзү юлы белән генә котылырга мөмкин икәнлеккә без ышанабыз“ дип белдергән.

ЛОНДОН, 28 гыйнвар. (ТАСС). Көньяк Африка Союзы парламентында, элекке премьер тарафыннан кертелгән һәм Германия белән хәзер үк солых төзүне таләп итә торган резолюция буенча фикер алышулар тәмам булды. Резолюция бары тик 22 тавыш күпчелек белән генә кире кагылды. Хөкүмәт тарафдарларының парламентта „бердәмлек“ күрсәтергә бөтен маташуларына карамастан, Герцог резолюциясен яклап 59 тавыш бирелде.

Соңгы фикер алышулар вактында Герцог үзенә каршы куелган гаепләүләргә җавап итеп,—Көньяк Африка Союзы тарафыннан сугышны дәвам иттерү „Германиянең хатын-кызларына һәм балаларына каршы җирәнеч җинаят“ булып тора, дип белдерде.

КАНАДА ПАРЛАМЕНТЫНА САЙЛАУЛАР

НЬЮ-ЙОРК, 28 гыйнвар. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Оттавадан хәбәр итүенә караганда, Канада хөкүмәтенең премьеры Кинг, Канада парламентына гомуми сайлаулар 26 нчы мартка билгеләнде, дип белдергән.

Гавас агентлыгының „Гомерлек каләме“.

И. Миксонов рәсме. (ТАСС фото-клишесе).

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 28 гыйнвар. (ТАСС). Кичә фронтта бер төрле яңалыкның да булмаганлыгы хәбәр ителә.

БЕРЛИН, 28 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы, фронтта Рейн елгасы буенда Альтейгем тирәсендә французларның пропаганда алып бару теләге белән, беренче тапкыр буларак, громкоговорительләрдән файдаланырга маташканлыкларын хәбәр итә.

БРЮССЕЛЬ, 28 гыйнвар. (ТАСС). „Журналь“ газетасының кичәге хәрби күзәтүендә болай диелә: „25 нче гыйнварда фронтта һаваның яхшы булуы авиация эше өчен уңайлы шартлар тудырды. Немец самолетлары көнчыгыш франция өстендә очтылар. Англия очучылары Германия өстендә очышлар үткәрделәр. Англия радиосының хәбәр итүенә караганда, самолетларның берсе үз базасына кайтмаган“.

БЕРЛИН, 28 гыйнвар. (ТАСС). Англия язучысы Герберт Уэльс Американың „Либерти“ журналында мәкалә урнаштырды. Бу мәкаләсендә ул Берлинне рәхимсез рәвештә бомбага тотуны таләп итә.

Германия информация бюросы монарга җавап итеп түбәндәгечә белдерә: „Берлингә ташланган бомбалар өчен Лондон ун өлеш артык күләмдә түләячәк. Кайбер тәҗрибәләре булган Англия очучылары, шундый омтылышның үзләре өчен нәрсәдән гыйбарәт булачагы турында, үзенең язу өстәле янында утыручы Уэльс әфәндегә караганда, яхшырак хөкем итә алалар“.

Япония—Америка мөнасәбәтләре турында Япония матбугаты

ТОКИО, 28 гыйнвар. (ТАСС). „Мияко“ газетасы үзенең баш мәкаләсендә, Япония белән Америка арасындагы сәүдә һәм навигация договорының хәрәкәт срогы тулу уңае белән һәр ике ил арасында договорсыз мөнасәбәтләр чоры башланганлыкны күрсәтеп үтә. Шушы ситуациядән килеп чыга торган мораль эффектка бәя биреп житкермәү ярамый,—ди газета,—чөнки Американың Япониягә карата теләсә нинди моментта үзенең бер яклы акты белән чикләү чаралары куллануы мөмкин. Билгеле, АКШ, договорны юкка чыгарып, Япониянең Кытайдагы активлыгын туктатырга маташа.

„Цюгай сиогио“ газетасы болай дип яза: „АКШ договорсыз хәл тудырып кына калмады, бәлки үзенең дингез флотын арттырырга һәм Гуам атавын ныгытырга да маташа. АКШ белән Япония арасында мөнасәбәтләрнең киләчәктә ничек дәвам итәчәгенә анализ ясарга кирәк. Билгеле, Көнчыгыш Азиядә яңа тәртип урнаштыруда Япониянең политикасын танудан АКШ хөкүмәте баш тартты. Американың яңа договор төзергә яки вакытлы килешү төзергә теләге булмавы факты безнең карашны раслый“.

Япония протестына Англиянең җавабы

ТОКИО, 28 гыйнвар. (ТАСС). Япониянең бөтен матбугаты, Англиянең Токиодагы илчесе Крейгиның кичә чит ил эшләре министре Аритага, Япония протесты уңае белән Англия хөкүмәтенең җавабын тапшырганлыгын хәбәр итә. Бу протест „Асама-Мару“ пароходы белән булган инцидент аркасында килеп чыккан иде. „Хоци“ газетасының күрсәтүенә караганда, Англия хөкүмәте, пароход халыкара хокук нигезендә тулысынча законлы рәвештә тотылган дип санап, үзенең бер яклы карашын алга сөрә. Хәзерге конфликтны бетерү өчен һәм киләчәктә шундый инцидентларны булдырмау өчен,—ди газета,—джентельмен килешүе төзеләчәк.

„Ници-Ници“ газетасының сүзләренә караганда, Крейги белән очрашканнан соң Арита чит ил эшләре министрлегендә киңәшмә җыйган. Бу киңәшмәдә тиешле чаралар хәзерләү мәсьәләсе хәл ителәчәк.

Браудерга каршы хөкем карары турында Америка журналы

НЬЮ-ЙОРК, 28 гыйнвар. (ТАСС) Америка җәмагатчелеге АКШ компартиясенең Үзәк Комитеты секретаре Браудерга каршы чыгарылган хөкем карарын киң рәвештә тикшерүне дәвам иттерә. „Нью-рипаблик“ журналы, шундый ук гаеп куелган башка кешеләрнең шул кадәр үк каты хөкемгә тартылуларына ышануы кыен дип, аеруча күрсәтеп үтә. Америка суды,—ди журнал,—чын җинаятчеләрнең эшләрен караудан баш тарта һәм шуның белән бергә АКШ ның күренекле җәмагат эшлеклесен 4 елга төрмәгә ябарга хөкем итә.

Журнал, Браудер, паспортлар турындагы законны бозуга карата үзенә куелган гаеп өчен хөкем ителүдән бигрәк, ул коммунистлар партиясендә торуы өчен хөкем ителде, дигән нәтиҗәгә килә.

Совет—Болгария мөнасәбәтләре турында Германия газетасы

БЕРЛИН, 28 гыйнвар. (ТАСС). „Кельнише цейтунг“ газетасы, Совет—Болгария арасында гадәттән тыш тиз арада тәмам булган экономик сөйләшүләр белән кызыксыну Болгариядә генә түгел, бәлки чит илләрдә дә бик зур булганлыкны яза. Бу аңлашыла, чөнки сүз сөйләшүләрнең объекты булып торган хуҗалык мәсьәләләре турында гына түгел, бәлки Болгария—Совет дуслыгын ныгыту турында да бара. Ирешелгән килешүнең нәтиҗәләре инде хәзер үк күренә. Совет газеталары София урамнарында иркекле рәвештә сатылалар. Совет китаплары сату магазины ачылды. Кино-театрларда совет фильмнәре күрсәтелә.

Болгар халкы Советлар Союзына тирән мәхәббәт белән карый һәм Болгария белән СССР арасындагы якынлыкны һәр яклап котлый. Ике дәүләт арасындагы якынлыкның болгар халкында ныклы нигезе бар. Болгар халкы рус халкын үзенең азат итүчесе дип саный. Бу исә болгар халкында Советлар Союзына карата нык рәвештә урнашкан мәхәббәтнең сәбәбе булып тора.

Совет галимнәре делегациясе Берлиндә

БЕРЛИН, 28 гыйнвар. (ТАСС). Германия мәгариф министрлегенең статс-секретаре Цшинч кичә совет галимнәренең Братиславадан Берлингә килгән делегациясе хөрмәтенә аш мәҗлесе үткәрде. Делегация составында СССР Совнаркомы янындагы Югары Мәктәп Эшләре Комитеты председателе иптәш Кафтанов һәм профессорлардан Виленский, Новиков, Еголин һәм Дейника иптәшләр бар. Аш мәҗлесендә СССР ның Германиядәге илчесе иптәш Шкварцев, чит ил эшләре министрлегенең секретаре Кепплер әфәнде, мәгариф министрлегенең югары мәктәпләр бүлеге җитәкчесе Менцель әфәнде, Көнчыгыш Европаны өйрәнү җәмгыяте председателе Курциус әфәнде, чит ил эшләре министрлегенең культура бүлеге мөдире Твардовский әфәнде һәм Германиянең күп кенә күренекле галимнәре булдылар. Совет галимнәре кич белән СССР ның илчесе иптәш Шкварцев белән берлектә, дәүләт опера театрында булдылар. Алар белән бергә Германиянең рәсми кешеләре дә булды. Кич 10 сәгаттә делегация Берлиннән Москвага чыгып китте. Вокзалда кунакларны СССР ның Германиядәге илчесе иптәш Шкварцев, Германия чит ил эшләре министрлегенең протокол бүлеге мөдире Дернберг һәм Германиянең хөкүмәт һәм культура учреждениеләренең күп кенә вәкилләре озаттылар.

СЕНАТОР БОРА ҮЛДЕ

НЬЮ-ЙОРК, (ТАСС). Каты авырудан соң сенатор Бора үлде.

Бора 1865 нче елда туган. Ул республикачылар партиясенең күренекле эшлеклесе иде һәм изоляционистлар оппозициясенә күп еллар буе җитәкчелек итте. Бора—1907 нче елдан бирле сенат члены.

Кытайда сугыш хәрәкәтләре

(ТАСС хәбәрләреннән)

Үзәк Кытайда

Чжэцзян провинциясенең төньяк өлешендә, Сяошань районында, япон гаскәрләренең соңгы көннәрдә 3.000 гә якын солдатлары үтерелгән. Кытай гаскәрләре кичә сугышып шәһәргә бәреп керделәр. Сугышлар төн уртасына кадәр дәвам итте. Цзяньтан елгасының төньяк ярында урнашкан япон артиллериясе кытайларның позицияләренә 200 дән артык снаряд атты.

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә кытай гаскәрләре, японнарның Янцзычендәге (Чжунсяньнән төньякта) гарнизонын әйләндереп алып, бәҗраны һаман кечерәйтә баралар.

Соңга калып алынган мәглүматларга караганда, кытай частьләре 19 нчы гыйнварда японнарның Гуаншуйдагы (Ханькоудан төньякка таба 150 километрда) позицияләренә атака ясаганнар. 3 сәгатьлек сугыштан соң японнар, кытай гаскәрләренең басымына түзә алмыйча, шәһәргә кереп качканнар. Шәһәргә керә торган урыннарда 3 километрдан артык җирдә тимер юл полотносы бозылган.

Төньяк Кытайда

Хэнань провинциясенең төньяк өлешендә булган сугыш нәтиҗәсендә японнарның 100 дән артык кешеләре үтерелде һәм яраланды. Алар чигенделәр. Шул ук көнне кытайларның икенче бер отряды японнарның Сяцзичендәге (Хуайциннан төньякта) позицияләренә атака ясады. Японнар Баойга чигенделәр.

*

26 нчы гыйнварда Кытай авиациясе Нанкин бистәләрендәге хәрби складларны бомбага тотты һәм японнарга зур зарар китерде. Шуннан соң кытай самолетлары японнарның Нанкин тирәсендә урнашкан гаскәрләрен бомбага тоттылар.

25 нче гыйнварда японнарның 6 самолеты Чжэцзян провинциясенең төньяк өлешендәге шоссе юллар чатында урнашкан Чэнсяньне бомбага тоттылар. Японнар 25 бомба ташладылар. 20 кеше үтерелде, 167 йорт җимерелде.

ХИЯНӘТЧЕ ВАН ЦЗИН-ВЕЙГӘ КАРШЫ

ЧУНЦИН, 28 гыйнвар. (ТАСС). Япония белән Ван Цзин-вей арасындагы килешүне хурлык тамгасы белән билгеләү турында Шаньси провинциясенең милли-политик советы утырышында карар кабул ителде.

Кытайның төрле җәмагат оешмалары, шул исәптән профсоюзлар, сәүдә палатасы, хатын-кызлар ассоциациясе, университетларның һәм урта мәктәпләрнең берләштерелгән ассоциациясе, фабрикаларның һәм заводларның берләштерелгән ассоциациясе һәм газеталарның берләштерелгән ассоциациясе, милли хөкүмәткә һәм бөтен кытай халкына телеграмма белән мөраҗәгать иттеләр. Бу телеграммада алар хиянәтче Ван Цзин-вейгә каты җәза бирүне таләп итәләр.

Телеграммада болай диелә: „Японнар һәм ван Цзин-вей тарафыннан үткәрелә торган „тынычлык өчен хәрәкәтнең“ Кытайны колыкка төшерергә юнәлдерелгән булуында безнең шигебез юк. Кытайның озак вакыт коралды каршылык күрсәтү политикасының илне азатлыкка һәм бәйсезлеккә китерәчәгенә без ышанабыз.

Безнең алда бер генә юл бар—ул, тәмам җиңгәнгә кадәр коралды каршылык күрсәтүне дәвам иттерү юлы. Дошманның һәм хиянәтчеләрнең интригаларын юк итү өчен, без Кытайның бердәмлеген көчәйтергә һәм ныгытырга тиешбез“.

Норвегия хезмәт ияләре сугыш уты кабызучыларга каршы

СТОКГОЛЬМ, (ТАСС). Шушы көннәрдә Порсгрунд шәһәрендә (Норвегия)коммунальниклар профсоюзы членнарының җыелышы булды. Җыелыштагылар бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә хөкүмәтнең нейтралитет саклавын һәм Норвегияне сугышка кертергә маташучыларга каршы кискен чаралар күрүен таләп итәләр.

Норвегиянең социал-демократик яшьләр союзы җитәкчелегенең Маннергейм Финляндиясенә ярдәм күрсәтергә карар чыгаруына каршы протест йөзеннән, Иляя шәһәренең социал-демократик яшьләр оешмасы председателе һәм секретаре Левенстен һәм Ульсберг социал-демократик союздан чыктылар һәм комсомолга керделәр.

Казандагы пионерлар һәм укучылар йортында яңа уку залы ачылды. РӘСЕМДӘ: алдагы планда Бауман районындагы 6 нчы мәктәпнең 7 нче класс укучысы Роза Баһаветдинова.

Б. Мясников фотосы. (ТатТАСС фотохроникасы).

Кролик совхозы

Чистайдан 2 километр ераклыктагы матур урман эчендә, элек Берсут җәнлек совхозының кролик фермасы урнашкан урында, нәселле кроликлар асрау өчен яңа совхоз оештырылды. Совхозда 750 баш ана кролик бар. 1942 нче елга ана кроликлар саның 1.500 башка җиткерергә билгеләнә.

Берсут совхозының кролик фермасы, совхоз булып оештырылганга кадәр, илгә, күп санда нәселле кроликлар бирде. Бу фермадан кроликлар Татарстан колхозларына, Украинага, Куйбышев, Чкалов, Киров, Чиләбе, Пермь өлкәләренә һәм башка өлкәләргә таралдылар. Соңгы 3 ел эчендә ферма нәсел үрчетү өчен 16 меңнән артык ана кролик сатты. Яхшы күрсәткечләр биргән өчен ферма үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашты һәм икенче дәрәҗәдәге дипломны алды.

1939 нчы елда ферма дәүләткә 190 килограмм бик кыйммәтле кролик мамыгы бирде. Быел яңа совхоз һәм аның иң яхшы 8 работнигы 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашырга теләүләре турында гариза бирделәр. Хәзерге вакытта күргәзмә өчен экспонатлар хәзерләнә. 16 рекордчы ана кролик сайлап алынды. Кролик тиреләренең һәм алардан эшләнгән әйберләрнең үрнәкләре сайлап алына. Кролик мамыгыннан хатын-кызлар өчен шәлләр, баш киемнәре, фуфайкалар, балалар бүрекләре, шарфлар, оекбашлар эшләнә.

Чистайдагы яңа совхоз Союздагы күп өлкәләрнең колхоз фермалары һәм колхозчылары өчен нәселле кроликлар житештереп торачак. (ТатТАСС).

Шоферлар хәзерләү

Лаиштагы автомәктәп чыгарыш ясады. Мәктәпне барлыгы 17 кеше тәмам итте. Шуларның 10 ысы хатын-кызлар.

Курсны бетергәннәрнең бер өлеше инде практикага җибәрелде. Укучылар арасында М. Кротова, А. Макосеева, М. Нефедова һәм башкалар укуны яхшы күрсәткечләр белән тәгәлләделәр. (ТатТАСС).

А. П. Чехов әсәрләре татар телендә

Соңгы өч елда Татгосиздат А. П. Чеховның татар телендә күп кенә әсәрләрен барлыгы 30 мең данә тиражда бастырып чыгарды. Чеховның „Жуликлар“ „Чокырда“, „Футлярле кеше“, „Налим“, „Ванька“ һәм башка хикәяләре басылды.

Хәзер А. П. Чеховның иң атаклы әсәрләрен эченә алган китап производствога бирелде. Элек басып чыгарылган хикәяләрдән тыш, бу китапка „6 нчы номерлы палата“, „Крыжовник“, „Репетитор“, „Жалоба кнәгәсе“ һәм башка хикәяләр кертелде. Китап 10 мең данәдә басыла. Аның күләме 16 табак исәпләнә.

Колхозчыларның үзара ярдәмләшү кассалары

Кукмара районында 33 колхозда колхозчыларның үзара ярдәмләшү кассалары оештырылды. Кассаларда 2.153 колхозчы член булып тора.

1939 нчы елда колхозчыларның үзара ярдәмләшү кассалары, 35 кызыл армеец семьясенә һәм 52 инвалидка материаль ярдәм күрсәтеп, аларга 4.000 сум пособие бирделәр. Моннан тыш, үзара ярдәмләшү кассалары 22 ятим баланы тәрбиялиләр. Бу эшкә инде 2.340 сум расход тотылды.

Бакчадан 3.200 сум доход

Арча районы „Авангард“ колхозында 16 гектар мәйданнан торган җиләк-җимеш бакчасы бар. Анда алма, чия, кура җиләге, кара карлыган, кызыл карлыган агачлары үсә. Зур тәҗрибәле бакчачы—65 яшьлек иптәш Бәширов Сабир бакча агачларына зур әһәмият белән тәрбияләп үстерә.

Колхоз, 1939 нчы елда бу бакчада үстерелгән җиләк-җимешне сатудан 3.200 сум доход алды.

ТӨЗӘТҮ

„Кызыл Татарстан“ның 27 нче гыйнвардагы номерында, 4 нче битнең 1 нче баганасындагы „Минин һәм Пожарский“ дигән рецензиянең 3 нче һәм 6 нчы абзацындагы „Новгород“ сүзен „Нижегород“ дип, 8 нче абзацтагы „Диванов“ ны „Ливанов“ дип төзәтеп укырга кирәк.

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) ның Бауман райкомының оештыру - инструкторлык бүлеге түбәндәгеләрнең райкомга керүләрен яки адресларын белдерүләрен сорый:

1) Альшина К. Әхтәмовна. 1902 нче елда туган, 1932 нче елдан ВКП(б) членлыгына кандидат, элек язу машиналары заводында эшләгән.

2) Анисимов Иван Васильевич. 1902 нче елда туган, 1937 нче елдан ВКП(б) членлыгына кандидат, элек Бауман райжилуправлениесенең 17 нче йорт идарәсендә эшләгән.

Җаваплы редактор һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Хезмәт ияләренең Казан Шәһәр Советы башкарма комитеты Шәһәр Советы депутаты иптәш

ИВАН СТЕПАНОВИЧ СМИРНОВНЫҢ

каты авырудан соң шушы ел, 28 нче гыйнварда вакытсыз үлүен тирән кайгы белән белдерә һәм аның семьясенең кайгысын уртаклаша.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Бүген көндез 12 сәгаттә һәм кич
КАЧКЫН
Талоннар: көндез 70, кич 71.
Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына. Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.
48—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
30 нчы гыйнварда көндез һәм кич (талоннар: 18 һәм 88), һәм 1 нче февральдә
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 30 нчы гыйнварда спектакль булмый.
31 нче гыйнварда, шулай ук 1 һәм 2 нче февральдә ПРЕМЬЕРА
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ“
Талоннар: 105, 106 һәм 107.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген көндез 12 сәгаттә һәм кич
Москва 4 нче труппасының соңгы гастрольләре
ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән
Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12-30, 2-45, 7-45 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ДУСЛАР
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	БАЙ КӘЛӘШ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич УКЫТУЧЫ. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	Степан Разин

КИРӘК:
ГИДУВ ка даими эшкә БУХГАЛТЕРЛАР, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, КОЧЕГАРЛАР, СЛЕСАРЬЛАР һәм ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР. Казан, Комлев урамы, 11.
151—2—1

Казан Авиация институтына даими эшкә БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ, КАРТОТЕКАЧЫ, ЧЕРТЕЖЧЫ, чит илләрдә чыга торган журналларны ТӘРҖЕМӘ ИТҮЧЕ, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, КИЕМ ЭЛГЕЧЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, ОХРАННИКЛАР, МЕТАЛЛ ЮНУЧЫЛАР, ЖИТЕШТЕРҮ БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ УРЫНБАСАРЫ, кадрлар учеты буенча СТАТИСТИК һәм ҮТӘҮЧЕ, ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, 6—7 нче РАЗРЯД СЛЕСАРЬЛАР, 6—7 нче РАЗРЯД ТОКАРЬЛАР һәм сантехника буенча СЛЕСАРЬЛАР КИРӘК. Институтның кадрлар бүлегенә килергә. Казан, Миславский урамы, 10.
128—2—1

Вахитов исемендәге жиркомбинатка ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОРЛАР, МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЛАРЫ, МАТЕРИАЛЬ ГРУППА ХИСАПЧЫСЫ, ФИНАНСИСТ, ИНЖЕНЕР-МЕХАНИК, ИНЖЕНЕР ТЕХНОЛОГ-ХИМИК, ТЕХНИК-КОНСТРУКТОР-МЕХАНИК, ЧЕРТЕЖЧЫЛАР, БАЛТА ОСТАЛАРЫ, ПИЧ ЧЫГАРУЧЫЛАР, ЯРДӘМЧЕ РАМЩИКЛАР КОЧЕГАРЛАР, ПРЕССТА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, САНТЕХНИКА БУЕНЧА ИНЖЕНЕР, производство эшләре буенча БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОР, шулай ук ТОКАРЬЛАР, ГЕНЕРАТОРЧЫ ЯРДӘМЧЕЛӘРЕ һәм 3, 4, 5, 6. 7 нче разряд СЛЕСАРЬЛАР. Комбинатның кадрлар бүлегенә килергә Тукай урамы, 152.
150—2—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2498 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 409.